**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 27 декабрендәге 5380 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2018 елның 13 ноябрендәге 5805 номерлы**
**«Социаль кулланылыштагы торак фондының**
**торак урыннарын наемга алу шартнамәләре нигезендә**
**торак урыннар алуга мохтаҗ гражданнарны исәпкә кую буенча**
**муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын**
**раслау турында»гы карарына**
**үзгәрешләр кертү хакында**

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 13 ноябрендәге 5805 номерлы «Социаль кулланылыштагы торак фондының торак урыннарын наемга алу шартнамәләре нигезендә торак урыннар алуга мохтаҗ гражданнарны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карарын гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 13 ноябрендәге 5805 номерлы карары (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2019 елның 19 июнендәге 2207 номерлы, 2020 елның 6 августындагы 2148 номерлы, 2021 елның 4 июнендәге 1401 номерлы, 2022 елның 2 февралендәге 350 номерлы, 2022 елның 12 декабрендәге 4319 номерлы, 2024 елның 28 февралендәге 673 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Социаль кулланылыштагы торак фондының торак урыннарын наемга алу шартнамәләре нигезендә торак урыннар алуга мохтаҗ гражданнарны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.3.2, 2.3.2, 2.5.1, 2.5.2, 2.5.3, 2.7.4, 2.13.2, 2.16.1, 2.16.2, 2.16.3, 2.16.4, 3.2.3, 3.3.2, 3.6.3.2, 3.7.1 пунктларга тиешле килешләрдәге «Республика порталы» сүзләреннән соң, тиешле килешләрдә куеп, «, Бердәм портал» сүзләрен өстәргә;

1.2. 1.4 пунктта «Республика реестрында» сүзләре алдыннан «Бердәм порталда» сүзләрен өстәргә;

1.3. 2.6.1 пунктта:

1.3.1. «13)» пунктчасын гамәлдән чыккан дип танырга;

1.3.2. пунктка түбәндәге эчтәлекле «23)» пунктчасын өстәргә:

«23) транспорт чарасы булу турында белешмәләр – Россия Эчке эшләр министрлыгы, Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы»;

1.4. 3 номерлы кушымтаның түбәндәге абзацыннан соң:

«□ Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинетка;»

түбәндәге абзацны өстәргә:

«□Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталындагы шәхси кабинетка».

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.Ә.Гыйниятуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**